Республика Татарстан
Глава Енабердинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423643, Менделеевский район, д. Енабердино,
ул. Новая, д 10а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге Башлыгы

423643, Менделеевск районы, Енабердино авылы,
Яна урамы, 10а

тел./факс 8/85549/3-56-29, E-mail: Enbrd.Men@tatar.ru,
http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/enaberdinskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.11. 2023 ел № 46

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында граждaннар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,
КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 27 ноябре 13.00 сәг. Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2023 елның 27 ноябре 16.00 сәг. Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Җыенның беренче этабын уздыру урыны итеп Енабердино авылы, Мәктәп урамы, 1А йорты адресы буенча урнашкан Енабердино урта белем бирү мәктәбен, икенче этабын уздыру урыны итеп Енабердино авылы, Клуб урамы 7 йорт адресы буенча урнашкан Енабердино авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Енабердино авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга

Беренче этап: Ленин урамы 1 йорттан 80 йортка кадәр;

Икенче этап: Майская урамы 1 йорттан 1 йортка кадәр, Яр буе урамы 1 йорттан 8 йортка кадәр, Яңа урам 1 йорттан 16 йортка кадәр, Клуб урамы 1 йорттан 4 йортка кадәр, Мәктәп урамы 1 йорттан 9 йортка кадәр Яшьләр урамы 9 йорт

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, югары һәм урта уку йортларында көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән тыш, ә 1 төркем инвалидлардан 500 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

Енабердино урта гомуми белем бирү мәктәбенә тротуар буйлап урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру;
- 3 данә янгынга каршы колонкалар сатып алу һәм урнаштыру;
- 3 данә янгынга каршы гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;
- 3 берәмлек чүп контейнеры сатып алу;
- юлларны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

8. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә

Енабердино авыл җирлеге башлыгы вазифаларын башкаручы Скворцова Е.Ю.